| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

№ 147/о

П Р И К А З — Б О Е Р Ы К

«06» 09 2016

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 24 мартындагы “2016 елга күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча Кыска вакытлы планга кертелгән эш төрләре буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик күләмдәге бәяләрен раслау турында” № 60/о боерыгы белән расланган 2016 елга күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча Кыска вакытлы планга кертелгән эш төрләре буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик күләмдәге бәяләренә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 24 мартындагы “2016 елга күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча Кыска вакытлы планга кертелгән эш төрләре буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик күләмдәге бәяләрен раслау турында” № 60/о боерыгы белән расланган 2016 елга күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча Кыска вакытлы планга кертелгән эш төрләре буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик күләмдәге бәяләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“Фасадларны җылыту һәм ремонтлау” дигән 1 бүлектә түбәндәге эш төрләрен өстәргә:

| № п/п | Боерык буенча | Эшләрнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч бәясе, 2016, сумнарда, |
|---|---|---|---|---|

| | № | | | НДС белән |
|---|---|---|---|---|
| “43[1] | 1.8.6. | Кирпеч диварларның ярыкларын арматурадан һәм базальтпластик бәйләмнә-реннән файдаланып ремонтлау | ярыкның п.м. | 6 990 |
| 43[2] | 1.8.7. | Кирпеч диварларны базальтпластик бәйләмнәреннән файдаланып ныгыту | диварның кв. метры | 1 673”. |

“Лифт җайланмасын ремонтлау һәм алмаштыру, лифт шахталарын ремонтлау” дигән 8 бүлектә түбәндәге эш төрләрен өстәргә:

| № п/п | Боерык буенча № | Эшләрнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч бәясе, 2016, сумнарда, НДС белән |
|---|---|---|---|---|
| “202₁ | 8.8 | Лифт шахтасын һәм 9 катка исәпләнгән пассажирлык лифтының машина бинасын, технологик җайланма өчен нигезләр урнаштырып, щитларны һәм кертеп корылган мәйданнарның блокларын монтажлап, кыстыргыч детальләр, анкерлар урнаштырып, металл өслекләрне янгынга каршы өслек белән тышлап, буяп һ.б. ремонтлау | 1 шахта | 279848”; |

“Гомумтөзелеш эшләре” дигән 9 бүлектә түбәндәге эш төрләрен өстәргә:

| № п/п | Боерык буенча № | Эшләрнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч бәясе, 2016, сумнарда, НДС белән |
|---|---|---|---|---|
| “218 | 9.16 | Кирпеч йортның подъездын ремонтлау (2 катлы, 1 | йортның гомуми | |

______________________________

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | подъездлы) | мәйданыннан кв. метры | 373,47”; |

түбәндәге эчтәлекле 10, 11 бүлекләрен өстәргә:

| № п/п | Боерык буенча № | Эшләрнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч бәясе, 2016, сумнарда, НДС белән |
|---|---|---|---|---|
| | 10. | **Энергетик тикшерү** | | |
| 219. | 10.1. | Энергетик тикшерү һәм энергетика паспортын эшләү | йортның төзелеш күләменең м3 | 2,34 |
| | 11 | Техник яктан инвентарьлаштыру | | |
| 220 | 11.1 | Техник яктан инвентарьлаштыру һәм техник паспорт әзерләү | йортның гомуми мәйданыннан кв. метры | 25,86”; |

искәрмәне түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

“7.***** Лифт җайланмасын ремонтлаганда һәм алмаштырганда лифт шахталарын һәм машина бүлеген ремонтлау буенча эшләр комплексы исәпкә алынды (чокыр идәннәре, каналлар, катлаулы чыгырлар урнаштыру, штукатурканы ремонтлау һәм диварларны буяу һ.б. (8.1.1-8.1.3, 8.4.1-8.6.2 п.п.)).”.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага әлеге беорыкның, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага шушы боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлеше буенча министрның беренче урынбасары А.М. Фроловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

ОТДЕЛ РЕГЛАМЕНТА И КОНТРОЛЯ №1